| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

«24» апреля 2020 с. Тюлячи № 195

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 декабрендәге 761 номерлы «2020 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган Теләче муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла торган) муниципаль хезмәт күрсәтүләргә (эшләргә) норматив чыгымнарны раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда кулланыла торган, муниципаль учреждениеләр, китапханәләр, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару хакының нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 сентябрендәге 864 номерлы һәм «Муниципаль учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 елның 5 сентябрендәге 638 номерлы карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 декабрендәге 761 номерлы «2020 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган Теләче муниципаль районы мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган муниципаль хезмәт күрсәтүләргә норматив чыгымнарны раслау турында» карарына түбәндәге редакциядә бәян итеп, үхгәреш кертергә:

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 31 декабрендәге
761 номерлы карарына
кушымта

2020 елга Теләче муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә норматив чыгымнар

| № т/б | Учреждение исеме | Хезмәтнең исеме | Норматив чыгымнар, сумнар | Елга хезмәт күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Музейлар | Музей предметларын, музей коллекцияләрен иҗтимагый күрсәтү | 317,12 | 2600 | берәмлек |
| 2 | Китапханәләр | Китапханәдән кулланучыларга китапханә, библиографик һәм мәгълүмати хезмәт күрсәтү | 99,72 | 130581 | берәмлек |
| 3 | Клуб тибындагы учреждениеләр | Кинофильмнар күрсәтү, клуб формированиеләре һәм үзешчән халык иҗаты формированиеләре эшчәнлеген оештыру | 301,34 | 130022 | берәмлек |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең территориаль үсеш һәм инвестиция эшчәнлеге буенча урынбасары И.Ә. Миңнегуловка йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов